**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 9 июнь № 384

г. Казань

Федераль милектә булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләрен ясау өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарын билгеләү турында

«Федераль милектә булган су объектларында ясалган ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 19 июль, ФЗ-246 нчы Федераль закон (алга таба – ФЗ-246 нчы Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгын түбәндәгеләргә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы итеп билгеләргә:

федераль милектә булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлеге ясау өчен рөхсәт проектын (алга таба – Рөхсәт проекты) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәнфәгатьле органнарына килештерүгә җибәрү;

ФЗ-246 нчы Федераль законның 4 статьясындагы 10 өлештә күздә тотылган очракларда Рөхсәт проекты буенча күрсәтмәләр җибәргән дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары катнашында килештерү комиссиясе төзү турында карар кабул итү;

ФЗ-246 нчы Федераль законның 4 статьясындагы 10 өлештә күздә тотылган очракларда килештерү комиссиясенең эшен оештыру;

Рөхсәт проектын килештерү;

ФЗ-246 нчы Федераль законның 5 статьясындагы 2 өлешнең 1 һәм 2 нче пунктларында күздә тотылган очраклардан тыш, федераль милектә булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир

кишәрлекләрен ясау өчен рөхсәт бирү яисә, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге рөхсәтне бирүдән баш тарту.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын түбәндәгеләргә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы итеп билгеләргә:

ФЗ-246 нчы Федераль законның 9 статьясындагы 4.1 өлешнең 2 нче пунктында күздә тотылган очракта, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә ясалма җир кишәрлегенең планлаштырыла торган чикләрендә территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итү;

территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы 10 өлештә күрсәтелгән таләпләргә туры килүенә тикшерү үткәрү;

ФЗ-246 нчы Федераль законның 9 статьясындагы 4.1 өлешнең 2 нче пунктында күздә тотылган очракта, тикшерү нәтиҗәләре буенча әзерләнгән документларны раслауга җибәрү турында яки әлеге документларны кире кагу хакында һәм аларны эшләп бетерергә җибәрү турында карар кабул итү;

ФЗ-246 нчы Федераль законның 9 статьясындагы 4.1 өлешнең 2 нче пунктында күздә тотылган очракта, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә территорияләренә карата әлеге документлар эшләнгән җирлекләрнең, шәһәр округының җирле үзидарә органнары белән әзерләнгән документларны килештерүне тәэмин итү;

ФЗ-246 нчы Федераль законның 9 статьясындагы 4.1 өлешнең 2 нче пунктында күздә тотылган очракта, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә территорияне планлаштыру документларын раслау хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты проектын әзерләү;

билгеләнгән тәртиптә инженерлык тикшеренүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы үткәрүне оештыру;

ФЗ-246 нчы Федераль законның 11 статьясындагы 2 өлешнең 2 нче пунктында күздә тотылган очракта, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге ясаган очракта, ясалма җир кишәрлеге ясау эшләрен үткәрүгә рөхсәт бирү яки әлеге рөхсәтне бирүдән баш тарту;

ФЗ-246 нчы Федераль законның 12 статьясындагы 3 нче пунктта күздә тотылган очракта, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә Татарстан Республикасының ике һәм аннан да күбрәк муниципаль берәмлеге (шәһәр округы, муниципаль районы) территориясендә ясалма җир кишәрлеге ясаган очракта, ясалма рәвештә ясалган җир кишәрлеген эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү яки әлеге рөхсәтне бирүдән баш тарту.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын түбәндәгеләргә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы итеп билгеләргә:

ясалма җир кишәрлеген ясау турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион оештыру;

ясалма җир кишәрлеген ясау турында шартнамә төзү;

ФЗ-246 нчы Федераль законның 13 статьясындагы 1 өлешнең 2 нче пунктында күздә тотылган очракта, республика бюджеты акчасы исәбеннән ясалма рәвештә ясалган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасының милек хокукын теркәүне гамәлгә ашыру.

4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карар үз көченә кергән көннән соң өч ай эчендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

федераль милектә булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләрен ясау белән бәйле тиешле вәкаләтләрне йөкләү өлешендә норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү;

федераль милектә булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында ясалма җир кишәрлекләрен ясау буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча тиешле административ регламентларны раслау;

әлеге министрлыкларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча расланган административ регламентларны бастыру.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\384.docx